Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Яңа Иштирәк авылы җирлегендә «2022 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Яңа Иштирәк авыл җирлегенең Яңа Иштирәк авылында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану турында» 2021 елның 20 ноябрендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

КАРАР

2022 елның 3 марты № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Яңа Иштирәк авыл җирлегенең Яңа Иштирәк авылында 2022 елның 3 мартында «2022 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Яңа Иштирәк авыл җирлеге Яңа Иштирәк авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү һәм алардан файдалану турында» мәсьәлә буенча 2021 елның 20 ноябрендәге 2 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Яңа Иштирәк авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән килешәсезме?» соравы буенча узган халык җыенының беркетмәсе төзелде, аерым алганда:

2 пунктның 2 абзацында «-Яңа Иштирәк авылында су линиясе һәм янгын гидрантлары төзү;» сүзләрен «-Яңа Иштирәк авылында Совет урамы, Шоссейная урамы буенча янгын гидрантлары урнаштыру;» сүзләренә алмаштырырга,

2 пунктның 4 абзацында «җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, әлеге кагыйдәләргә туры китереп, җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:» сүзләрен «җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы булып, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең үтемлелеген тәэмин итү таләпләрен үтәү, әлеге кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру тора» сүзләренә алмаштырырга;

- Яңа Иштирәк авылының Садовая урамы буенча иске агачларны кисү;

2 пуктны түбәндәге эчтәлекле 5 абзац белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру»;

2 пуктны түбәндәге эчтәлекле 6 абзац белән тулыландырырга:

«-Садовая урамында су линиясе төзү;»

«ӘЙЕ» «ЮК».

Халык җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 452 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 229 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучылар бертавыштан «Әйе»позициясе өчен тавыш бирделәр.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Яңа Иштирәк авыл җирлегенең Яңа Иштирәк авылында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Яңа Иштирәк авыл җирлегенең Яңа Иштирәк авылында халык җыены карарына «2022 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Яңа Иштирәк авыл җирлеге Яңа Иштирәк авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында» 2021 елның 20 ноябрендәге 2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 2 абзацында «-Яңа Иштирәк авылында су линиясе һәм янгын гидрантлары төзү;» сүзләрен «-Яңа Иштирәк авылында Совет урамы, Шоссейная урамы буенча янгын гидрантлары урнаштыру;» сүзләренә алмаштырырга,

2 пунктның 4 абзацында «җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, әлеге кагыйдәләргә туры китереп, җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:» сүзләрен «җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы булып, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең үтемлелеген тәэмин итү таләпләрен үтәү, әлеге кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру тора» сүзләренә алмаштырырга

- Яңа Иштирәк авылының Садовая урамы буенча иске агачларны кисү;

2 пуктны түбәндәге эчтәлекле 5 абзац белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру»;

2 пуктны түбәндәге эчтәлекле 6 абзац белән тулыландырырга:

«-Садовая урамында су линиясе төзү;»

2. Әлеге карарны Лениногорск районы, Яңа Иштирәк авылы, Үзәк урам, 7 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
Яңа Иштирәк авыл җирлеге башлыгы Г.Р.Мәүлетова